| ГЛАВА АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2022 г. Агрыз № 94

### Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен Килештерү проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24 статьялары, Әгерҗе муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 27.06.2018 ел, № 28-2 карары белән расланган гавами тыңлауларны, иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлегендәге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен Килештерү проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләргә

2. Билгеләләргә:

2.1. Иҗтимагый фикер алышуларны үткәрү вакыты – 2022 елның 12 декабреннән 2023 елның 12 гыйнварына кадәр;

2.2. Планлаштыру проектын һәм сызыклы объектны межанлау проектын бастыру өчен рәсми сайт - http://agryz.tatarstan.ru.

Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы-Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлеге башкарма комитеты.

3. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

3.1. Әлеге карарны 2022 елның 12 декабрендә Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында бастырып чыгарырга http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru шулай ук Әгерҗе муниципаль районы Советының мәгълүмат стендларында урнаштырырга;

3.2. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районы сайтында Иҗтимагый фикер алышуларның башлануы турындагы хәбәрне бастырып чыгарырга http://agryz.tatarstan.ru шулай ук Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга;

3.3. Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлегенең беренче катында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен Килештерү проекты буенча

экспозиция ачу, шулай ук 2022 елның 12 декабреннән 2023 елның 12 гыйнварына кадәр экспозиция белән килүчеләрне таныштыру мөмкинлеген тәэмин итү;

3.4. 2022 елның 12 декабреннән 2023 елның 12 гыйнварына кадәр тикшерелә торган проект буенча, тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне, идентификация узган килүчеләрдән кабул итәргә:

- Татарстан Республикасы, Тирсә авыл җирлеге, Терси авылы, Мәктәп урамы, 3 нче йорт адресы буенча язма формада;

- Татарстан Республикасы, Тирсә авыл җирлеге, Терси авылы, Мәктәп урамы, 3 нче йорт адресы буенча проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабына язылу аша.

3.5. Проект буенча фикер алышу нәтиҗәләре буенча иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсе һәм иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә.

3.6. 2023 елның 13 гыйнварында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районы сайтында Иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырып чыгарырга http://agryz.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Шәриповка йөкләргә.

**А.Р. ВӘЛИЕВ**

Л.С. Барекова